Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Муниципаль бюджет гомуми
белем бирү учреждениесе
“Киров урта гомуми белем бирү мәктәбе”

Җиһангирова Наилә Мисхәт кызы

# “*Синең бер тамчы караңа тулы кояш сыйган бит!”*

*Шагыйрь Ләбиб Леронның 55 яшьлек юбилей кичәсе*

Язучыны, шагыйрьне үзхалкытудыра.Ул аны үстерә,аңа канатлар бирә,очышын борчылып һәм куанып күзәтә - зур әдипләре булган халыклар,үз чиратында канатлы һәм мәңгелек.Безнең татар халкы үтә үзенчәлекле язмышлы, фаҗигале тарихы, даими үткәне, яңарышка юл тоткан бүгенгесе һәм киләчәгенә өмете булган бер халык.Безнең көннәрдә исә аның гали рухын, әле дә яшеренеп яткан биниһая көчен, мөмкинлекләрен күрсәтер җан көзгесе булган язучыларыбыз бигрәк тә кирәк. Шөкер, алар бар. Аларбезнеяратып, үзитепкунакка кайтканнар. Бүгентанылганязучыбыз, драматург-авылдашыбыз, Татарстан язучылар берлеге рәисе- Данил абый Салихов һәм 55 яшьлек юбилеен каршылаучы, якташыбыз-авылдашыбыз, яраткан шагыйребез –Ләбиб абый Лерон бездә кунакта. Әйдәгез аларны сәхнәгә чакырыйк.

**1 а.б.** Исәнмесез, хәерле көн

Очрашулар шулай башлана

Сезнең белән очрашуга,

Күңелебез шундый шатлана.

**2а.б.** Карап тормый ара еракка

Килдегез Сез безгә кунакка

Дуслык безнең тормыш үзәге

Дуслык безнең бәйрәм бизәге.

***башкаруында “__________________” җыры Сезгә олы ихтирамыбыз булып яңгырасын.***

**1.а.б.** Хөрмәтле кунаклар, кадерле укытучылар, укучылар! Чын йөрәктән чыккан серләребезне сөйләшер өчен,

“*Синеңбертамчыкараңа*

*Тулы кояшсыйган бит!”*

дип исемләнгән Ләбиб абый Леронның юбилей кичәсенә җыелдык.

**2.а.б.** Татар халкы зур шәхесләр белән

Танылган ул гомер-гомергә

Бүгендә без татар кызларының

Язмаларын салыйк күңелгә.

**1.а.б**. Серле ут син – каләм уты

Янасың көн дә төннәр.

Сүндерә алмый бит сине

Хәтта давыллар, җилләр.

**2.а.б.** Һәркемнең тормышында җуелмас якты эз калдырган, искә төшкән саен күңелгә җылылык бирә торган кешеләр була. Аның белән кабат күрешү үз көчеңә ышаныч, дәрт тудыра, кешеләргә булган ихтирамыңны арттыра, рухыңа көч,җаныңа дәрман бирә. Аның белән үткәннәр хакында сөйләшәсеңме,киләчәк турында хыялланасыңмы, ничектер баеп,ныгып каласың. Безнең өчен әнә шундый хөрмәтле, ихтирамга лаеклы, кызыклы шәхес ул авылдашыбыз, якташыбыз Данил абый Салихов.

Ә хәзер сүзне Татарстан язучылар берлеге рәисе Данил абый Салихов ала. Рәхим итегез!

- Шагыйрь, абый, әти, бабай.  Хөрмәтле кунаклар, бүген безнең бәйрәмебез шушы исемнәрне берләштерүче авылдашыбыз, татар халкының йөзек кашы булып торучы Ләбиб Леронга  багышлана.

-Ләбиб Лерон 1961 елның 17 ноябрендә Татарстанның Мөслим районы Түреш (Иске Карамалы) авылында туа, балачагы һәм үсмер чоры Актаныш районының Олыймән авылында уза.

-Ә хәзер сүзне аның балачак дусты авылдашы, дусты Каюмов Азат абыйга бирәбез.

К.н.

- Яшьлек калган, истәлекләр калган,
  Яза-яза тулган көндәлек.
  Кайсыелныңкайсыкөнегенә,
  Түгелмикәнсагыныпсөйләрлек.

-9,10 класста белемне Киров урта мәктәбендә ала. Класс җитәкчеләре Рузалия апа Галлямова да бүген бездә кунакта. Ул чорларны искә төшерү өчен сүзне Рузалия апа сезгә бирик әле. Укытучылары- Шамил Латыйпов, Мәдәния Мансур кызы, Әфүзә Мирзәхмәт кызының да әйтер сүзләре бардыр. Рзхим итегез.

К.н.

-Ләбиб Лерон 1984 елда Казан дәүләт университетын тәмамлый. 2002 елда Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә лаек була. 1994 елдан – Шәйхи Маннур, 2000 елда- Абдулла Алиш, 2006 елда- Фатыйх Хөсни, 2007 елда- Муса Җәлил исемендәге республика премияләре лауреаты.

- 2010 елда Төркиянең Самсун шәһәрендә булып узган шигырь фестивалендә, 2011 елда Сербиянең Белград шәһәрендә үткән Бөтендөнья Язучылары конгрессында катнаша.

- Ләбиб Лерон хәзерге вакытта 15 китап авторы.
- “Безнең мирас” журналының баш мөхәррире.

-Шагыйрь каләме кәгазь өстеннән йөгерә. Чөнки аның кешеләргә ул гына әйтә алган кадерле сүзләре бар. Коры фикерләр белән генә түгел, шулар янына хис, тойгы да өстәп эшли ул моны. Менә ни өчен аның сүзе бик күпкә үтемлерәк була. Шагыйрь каләме бары тик игелекле фикерләр, тойгылар гына белдерсә, бүгенгебез, киләчәгебез имин, матур булыр.

-Ләбиб Лерон аеруча балалар өчен күп яза.Башлангыч классларның мәктәп программаларына да аның иҗаты кертелгән. Аның шигырьләре укучылар өчен җиңел һәм аңлаешлы итеп язылган. Ә күпләр аның шигырьләрен яттан белә.

**(“___________________________________” шигырьләресөйләнелә.)**

**2нче алыпбаручы.**
Тиздән көтеп алган Яңа ел бәйрәме җитәчәк. Безнең укучыларыбыз мәктәбебездә уздырылачак Чыршы бәйрәмендә Ләбиб абыйның “Яңа ел биштәре”әсәрен тәкъдим итәргә җыена.

- Ә хәзер сүзне укучыларыбызга бирик.

- Ләбиб Леронның 15 китабы дөнья күрде, ә аларның кайберләрен сезнең алдыгызда китап күргәзмәсендә күрәсез. Аның 20 дән артык шигыре көйгә салынган, шуларның берсен әле яңа гына укучылар башкаруында тыңлап үттегез, тагын берничәсен кичә барышында ишетерсез.

- Ә хәзер котлау өчен сүз мәктәп директоры Гөлназ Сәгыйтьҗан кызына бирелә.

- К.н.

- Котлауларны дәвам итеп сүз авылыбыз башлыгы Гафуров Айваз Әбсогет улына бирелә.

- Авылыбызның мәдәният йорты директоры Хуҗина Алсу һәм авылыбызның китапханә мөдире Сибгатуллина Энҗенең дә Данил абыйга, Ләбиб абыйларга әйтәсе җылы фикерләре бар. Рәхим итегез!

К.н.

- Үз халкының күңеленә

Иң яраклы ачкыч бул;

Биеклеккә менәр өчен

Ышанычлы баскыч бул.

**2.а.б.** Гаделлекне иман ит син ,

Хакыйкатьне кыйблаң ит.

Синең бер тамчы караңа

Тулы кояш сыйган бит

- Нәфис сүз. Укый Сабитов Руслан, Гыйлемова Фирдания.

К.н.

-Әдәм баласы бу дөньяда үзеннән күп нәрсә калдыра: затлы исемен, нәселен, мирасын. Габдулла Тукай болай дигән “Без шушуы олуг мәмләкәтебезнең сакчысы вә гражданы, вә бөтен мәгънәсе белән ватан хадиме булырга тиешлебез”.

–Әйе, затлы исем калдырсаң, киләчәк буын исемеңне ядкарь итеп сөйлиячәк. Ә язылган әсәрнең һәр юлы –васыять булырлык мирас. Безне бәхетле итеп, каршыбызда утырган очрашу кунагыбыз танылган шагыйребез Ләбиб Лерон да бу исемгә лаеклы.

Юбилеегыз белән Ләбиб абый!

Сезнең өчен бүгенге көн гаять шатлыклы да һәм бераз гына, бәлки, сагышлы да.
Йөзләрегездә нур уйнап торганда, Сезнең өчен ул гомерегезнең бер җәе генә.Әле аның көзе дә, кышы да, кабат язы да булыр. Шушыизгеминутлардаяшәүдәфтәрегезгәозын, тынычгомерязылсын, бүгенге ихлас теләкләр барсы да кабул булсыннар.

**(Бию.)**

**1нче алыпбаручы.**

Кабул итегез сез безнең ихлас теләкләрне,
Сәламәт булыгыз, рухыгыз һәрчак көчле булсын,
Шатландырып, җилкендереп йөрәкләрне
Күңелегездә бәхет хисе ташып торсын!

**2нче алыпбаручы.**

Килер еллар озын гомер бүләк ит сен,
Безнең өчен бик якын һәм кадерлесез!
Нәр яңа көн сезне кабат сөендерсен,
Уңышларның яңаларын алып килсен!

-Яши белү-сайран кылу түгел

Үзең салсаң гына зур юллар

Барып тоташа улсукмаклар;

Үзең яксаң гына тәнгә, җанга

Җылы бирә бит ул учаклар.

**2.а.б.** Яшик шулай бер-беребезне зурлап,

Туган җирне зурлыйк иң элек.

Гомер мизгел, гомер үтә-китә

Яхшылыкларгына мәңгелек.

**1.а.б.** Рәхмәт сезгә, мәңге шулай

Тыйнак гүзәл булып калыгыз

Югалтмыйчакүңел энжеләрен

Киләчәккә алып барыгыз.

- Ләбиб Леронның  шигырьләре сездә тагын да зур кызыксыну уяткандыр.Шундый аз вакытта гына аның иҗаты белән танышу мөмкин түгел. Яраткан шагыйребезнең иҗатын өйрәнүне дәресләрдә дәвам итәрбез. Ләбиб абый! Сезнең иҗатыгыз алдында баш иябез.

Туганда ук шагыйрь булып

Туу Сезгә насыйп булгандыр.

Гомер буе иҗат эше кылып

Чәчегезгә кырау кунганмы?

Тик шулайда һаман яшьсез әле

Олыгаю хисе кермәгән.

Әйтерсең лә борчу-мәшәкатьләр

Сезнең кырда бер дә йөрмәгән.

Сез түземсезлек белән көткән минутлар якынлашты. Укучылар , ә хәзер Ләбиб абыегызга  үзегезне  кызыксындырган сорауларны бирә аласыз.

(Сорауларга җавап бирә.  К.н.)

-Ләбиб абый! Без Сезгә киләчәктә дә иҗади уңышлар,сәламәтлек телибез. Безне яңа әсәрләрегез белән шатландырып торыгыз. Янып яшәгез һәм иҗат итегез!  Хәзер сүзне сезгә бирәбез. Бәлки безгә үзегезнең шигырьләрегезне укырсыз яисә әйтәсе киңәшләрегез бардыр. Рәхим итегез.

– Халкыбызның рухи дөньясын баетуда җуелмас эз калдырган шәхесләрнең төрле чорда Киров авылындагы мәктәптә белем алулары һәм иҗатлары белән горурланабыз. Әсәрләре белән илебезне, туган телебезне яратырга өйрәткән шәхесләргә багышланган кичәбезне Габдулла Тукайның “Туган тел” шигырен бергә җырлап тәмамлыйбыз.